| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» | | «ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

П О С Т А Н О В Л Е Н И Е К А Р А Р

2022 елның 8» ноябре № 1123

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы мобилизацияләнгән гражданнарының гаиләләренә ярдәм итү чараларының исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләүне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә мобилизацион әзерлек һәм мобилизацияләү турында»1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Хәрби комиссарының «Мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 183 номерлы боерыгы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карарының 3 пункты нигезендә, 2022 елның 21 сентябреннән Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясенең иминлеген һәм милли мәнфәгатьләрен яклауга юнәлдерелгән өлешчә мобилизация игълан ителүен исәпкә алып, мобилизацияләнгән гражданнарның гаиләләренә ярдәм күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы мобилизацияләнгән гражданнары гаиләләренә ярдәм итү чараларының кушымта

итеп бирелгән исемлеген расларга.

2. Әлеге карарның гамәлләре 2022 елның 21 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://www.leninogorsk.tatarstan.ru) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), вакытлы матбугатта – «Лениногорские вести» газетасы аша халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

З. Г. Михайлова

Җитәкче

И.Р. Хәйбрахманов
5-44-72

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның «08» ноябрендәге 1123 номерлы карары белән расланды

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы мобилизацияләнгән гражданнары гаиләләренә ярдәм итү чаралары
исемлеге

1. Мобилизация буенча хәрби хезмәтенә һәм хәрби вакытта чакырылган гражданнар гаиләсендәге Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү учреждениеләрендә төп гомуми һәм урта гомуми белем алучы 1-11 сыйныф укучыларына түләүсез ике тапкыр кайнар ризык (иртәнге аш, төшке аш) белән тәэмин итү (мобилизация буена хәрби хезмәте узу чорына һәм хәрби вакытта гамәлдә).

2. Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен айлык ата-ана түләвеннән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районыннан мобилизация буенча хәрби хезмәткә һәм хәрби чорда алына торган гражданнар гаиләләрен азат итү (мобилизация буена хәрби хезмәте узу чорына һәм хәрби вакытта гамәлдә).

3. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмасына чираттан тыш кабул итү хокукын бирү (мобилизация буена хәрби хезмәте узу чорына һәм хәрби вакытта гамәлдә).